КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 апрель г.Казань № 1254

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтага үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче; 2016 ел, 24 февраль, 112 нче; 2016 ел, 15 апрель, 225 нче; 2016 ел, 8 май, 288 нче; 2016 ел, 22 июль, 498 нче; 2016 ел, 23 сентябрь, 681 нче; 2016 ел, 30 ноябрь, 884 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1053 нче; 2017 ел, 3 февраль, 59 нчы; 2017 ел, 26 май, 308 нче; 2017 ел, 21 июнь, 411 нче; 2017 ел, 26 июнь, 433 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 777 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 993 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1077 нче; 2018 ел, 19 гыйнвар, 18 нче; 2018 ел, 14 февраль, 87 нче; 2018 ел, 26 апрель,

285 нче; 2018 ел, 4 май, 318 нче; 2018 ел, 26 июнь, 519 нчы; 2018 ел, 22 сентябрь, 824 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1210 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 13 нче; 2019 ел, 2 апрель, 258 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 840 нчы; 2019 ел, 28 октябрь, 965 нче; 2019 ел, 12 ноябрь, 1035 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1134 нче; 2020 ел, 3 апрель, 254 нче; 2020 ел, 8 август, 668 нче; 2020 ел, 25 ноябрь, 1064 нче; 2020 ел, 8 декабрь, 1114 нче; 2020 ел, 11 декабрь, 1125 нче; 2020 ел, 18 декабрь, 1151 нче; 2021 ел, 12 март, 125 нче; 2021 ел, 27 март, 175 нче; 2021 ел, 21 июнь, 487 нче; 2021 ел, 6 ноябрь, 1052 нче; 2021 ел, 6 декабрь, 1166 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтага, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына
5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 декабрь, 1254 нче
карары редакциясендә)

2022 елга Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру чаралары планы («юл картасы»)

| Т/с | Төп чара исеме / «юл картасы» чарасы | Җаваплы башкаручы | Турыдан-туры көтелә торган нәтиҗә | Финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | шул исәптән | |
| | | | | | федераль бюджет | Татарстан Республикасы бюджеты |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыруга методик алымнар формалаштыру | | | | | | |
| 1.1. | Чит кеше каравына мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның яшәү шартларына карап һәм чит кеше каравына мохтаҗлык дәрәҗәләре буенча өйдә озак вакыт карау буенча социаль пакетка керә торган социаль хезмәт күрсәтүләр исемлеген һәм күләмен формалаштыру һәм раслау | ТР Хезмәт министрлыгы* | ТР МК карары | I квартал | - | агымдагы финанслау |
| 1.2. | Сынау үткәрелә торган муниципаль районнарда (шәһәр округларында) | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР МК карары | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |

*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 9 нчы биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | апробацияләнүен исәпкә алып, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеген актуальләштерү, Татарстан Республикасында хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү | | | | | |
| 1.3. | Татарстан Республикасында хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтүнең яңартылган тәртибе нигезендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләргә тарифлар әзерләү | ТР Хезмәт министрлыгы, РРҮ, ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты | ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 1.4. | Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында чит кеше каравына мохтаҗ гражданның (инвалидның) яшәү шартларына карап һәм чит кеше каравына мохтаҗ булу дәрәҗәләре буенча озак вакыт карау буенча социаль пакетка бәйле рәвештә, бер социаль хезмәткәргә йөкләнеш нормасын билгеләү | ТР МК, ТР Хезмәт министрлыгы | ТР МК карары | IV квартал | - | агымдагы финанслау |
| 1.5. | Озак вакыт карау кысыларында өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның социаль хезмәт күрсәтүгә һәм | ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | документлар формаларын апробацияләү нәтиҗәләре турында Россия Федера- | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләгәндә кулланыла торган документлар формаларын апробацияләү | | циясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат тапшыру (рәсми сорау буенча) | | | |
| 2. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы кысаларында ведомствоара хезмәттәшлек механизмнарын камилләштерү | | | | | | |
| 2.1. | Озак вакыт карау, социаль булышлык күрсәтеп торуга мохтаҗ гражданнар турында мәгълүмат алу, саклау, тапшыру һәм алмашу, озак вакыт карау кысаларында өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга хезмәтләр күрсәтү мониторингы өчен мәгълүмат системасын камилләштерү | ТР Цифра министрлыгы, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, «РММАҮ» ДАССУ | гомуми мәгълүмат ресурсы | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 2.2. | Медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары арасында озак вакыт карауга мохтаҗ һәм карау хезмәтләре күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар турында мәгълүмат алмашу, «Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» дәүләт казна учреждениесеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге – дәүләт учреждениесеннән карауга мохтаҗ гражданнар турында мәгълүмат алу, карау хезмәтләре күрсәтелүчеләр турындагы мәгълүматны саклау | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, РФ ПФның ТР буенча бүлеге, «Татарстан Республикасы буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» ДКУ | гомуми мәгълүмат ресурсларында озак вакыт карауга мохтаҗ һәм карау хезмәте күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар турында мәгълүмат | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 1. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыруга методик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру | | | | | | |
| 3.1. | Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә «Зәгыйфь өлкән яшьтәге кешеләрне карау. Россия тәкъдимнамә- | ТР ССМ, ДССУ | сынау үткәрелә торган муниципаль районнар (шәһәр округлары) терри- | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ләре» методик тәкъдимнамәләрен кулланышка кертү | | ториясендәге дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә методик тәкъдимнамәләрне 100 процент кертү, % | | | |
| 3.2. | өйдә һәм социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтә торган социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә «Зәгыйфь өлкән яшьтәге кешеләрне карау. Россия тәкъдимнамәләре» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертүдә методик булышлык күрсәтүне башкару | РРҮ | 45 муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә өйдә, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениеләрендә методик тәкъдимнамәләр нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтелүче өлкән яшьтәге зәгыйфь затларны карауны 100 процент колачлау | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 3.3. | «Карау мәктәбе» технологиясе буенча халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре, тернәкләндерүнең техник чараларын прокатка бирү пунктлары эшен оештыруга методик булышлык күрсәтүне гамәлгә ашыру | РРҮ | сынау үткәрелә торган муниципаль районнарда (шәһәр округларында) социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына методик булышлык күрсәтүне 100 процент колачлау | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 3.4. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең көндезге бүлекләрендә, инвалидларны реабилитацияләү үзәкләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтүдә методик булышлык күрсәтүне гамәлгә ашыру | РРҮ | сынау үткәрелә торган муниципаль районнарда (шәһәр округларында) социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына методик булышлык күрсәтүне 100 процент колачлау | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. Озак вакыт карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны ачыклауны һәм аларга карау хезмәтләре күрсәтүне оештыру | | | | | | |
| 4.1. | Озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ | барлык 45 муниципаль районда (шәһәр округында) озак вакыт карау системасын гамәлгә кертү | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| | | ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | Озак вакыт карауга мохтаҗ инвалидларның һәм эшкә сәләтле яшьтәге гражданнарның гомуми саныннан озак вакыт карау системасы кысаларында хезмәт күрсәтүдән файдаланучы эшкә сәләтле яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өлеше, % | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 4.2. | Социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләрне карау буенча индивидуаль планнар төзүне һәм тормышка ашыруны һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту, типлаштыру өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрдә хезмәткәрләр штатын арттыру | ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | ХСХККҮ хезмәткәрләре штатын 38 берәмлеккә арттыру | ел дәвамында | 17 586,3 | 4 125,2 |
| 4.3. | Чит тәрбиягә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны (инвалидларны) ачыклау | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ДССУ, СХКУ, РФ ПФның ТР буенча бүлеге, «Татарстан Республикасы буенча Медицина- | озак вакыт карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны проактив ачыклау нәтиҗәләре турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат бирү (рәсми сорау буенча) | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | социаль экспертиза баш бюросы» ДКУ | | | | |
| 4.4. | Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында озак вакыт карау кысаларында хезмәтләр күрсәтүне оештыру | ХСХККҮ | 4 906 кеше | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 5. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы кысаларында яңа технологияләр һәм эш формаларын кертү һәм булганнарын үстерү | | | | | | |
| 5.1. | Теләсә нинди оештыру-хокук формасындагы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан сиделкалар хезмәтләре күрсәтүне оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы, дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр | Теләсә нинди оештыру-хокук формасындагы юридик затлар һәм (яки) индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан күрсәтелә торган «Сиделка» хезмәте белән 207 кешене колачлау | ел дәвамында | 41 383,2 | 9 707,1 |
| 5.2. | Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар туганнарына өй шартларында карау, техник тернәкләндерү чараларын куллану күнекмәләрен өйрәтү өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләр тарафыннан «Карау мәктәбе» технологиясен тормышка ашыру | РРҮ, ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | 2022 ел ахырына 300 кешене укуга җәлеп итү | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 5.3. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрдә техник реабилитацияләү чаралары прокаты пунктларын урнаштыру | ХСХККҮ | 10 пункт | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 5.4. | Социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт учреждениеләре, коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмалар базасында өлкән яшьтәге гражданнар | ХСХККҮ, ИТҮ, ККСЮО | 100 кешедән кимрәк | ел дәвамында | 9 074,6 | 2 128,6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм инвалидлар өчен көндезге бүлекләр эшләү | | | | | |
| 5.5. | Авыл җирендә яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплексны үзәкләрнең «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында сатып алынган автотранспорты белән көндезге бүлекләргә (төркемнәргә) алып килү | ХСХККҮ | 8 муниципаль районда авыл җирендә яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны ХСХККҮ автотранспорты белән көндезге бүлекләргә (төркемнәргә) алып килү | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 6. Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләрен әзерләү (һөнәри белем бирү һәм һөнәри укыту) һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү | | | | | | |
| 6.1. | Һөнәри әзерлек һәм тематик камилләшү циклларында сәламәтлек саклау белгечләренә гериатрия, паллиатив ярдәм һәм медицина реабилитациясе нигезләрен өйрәтү: | ТР ССМ, югары һөнәри медицина белеме бирелә торган мәгариф учреждениеләре (килешү буенча), өстәмә һөнәри белем бирелә торган мәгариф учреждениеләре (килешү буенча), урта медицина һөнәри белем бирелә торган һөнәри мәгариф учреждениеләре (килешү буенча) | | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 6.1.1. | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының районара һәм шәһәр гериатрия кабинетлары табиб-терапевтларын (гомуми практика табибларын) КДМАнең терапия, гериатрия һәм гаилә медицинасы кафедрасында «Гериатрия» беренчел яңадан әзерләү циклларында укытуны оештыру | | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының гериатрия бүлекләрен һәм кабинетларын табиб кадрлары – 10 табиб белән комплектлау | | | |
| 6.1.2. | Табибларны КДМАнең терапия, гериатрия һәм гаилә медицинасы кафедрасында «Гериатриянең актуаль мәсьәләләре» квалификация күтәрү циклларында укытуны оештыру | | 10 табибны «Гериатриянең актуаль мәсьәләләре» квалификация күтәрү циклларында укыту | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1.3. | табибларны Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ өлкән пациентларда хроник авыру синдромы (ХАС)» интерактив белем бирү модульләре кысаларында укытуны оештыру | | паллиатив медицина ярдәменә мохтаҗ хроник авыру синдромлы пациентларга медицина ярдәме күрсәтү өлешендә 10 табибның квалификациясен күтәрү | | | |
| 6.1.4. | «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесендә «Өлкән яшьтәге һәм картлар яшендәге затларга медик-социаль ярдәм күрсәтү» һөнәри яңадан әзерләү циклларында урта медицина хезмәткәрләрен укытуны оештыру | | өлкән яшьтәге һәм картлар яшендәге затларга медицина ярдәме күрсәтү өлешендә 10 урта медицина хезмәткәре квалификациясен күтәрү | | | |
| 6.2. | Озак вакыт карау мәсьәләләре буенча социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт учреждениеләренең авыруларны караучыларын, социаль хезмәткәрләрен, кече медицина персоналын укыту | РРУ | социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең 100 хезмәткәрен озак вакыт карау мәсьәләләре буенча укыту | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 7. Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга озак вакыт карау буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын контрольдә тоту, өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проекты нәтиҗәләрен анализлау | | | | | | |
| 7.1. | Озак вакыт карау кысаларында хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшчәнлеген бәйсез бәяләү үткәрү | ТР Хезмәт министрлыгы каршындагы бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар | бәйсез бәяләү уздыру | ел дәвамында | - | агымдагы финанслау |
| 7.2. | Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга озак вакыт карау кысаларында күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтәлешен мониторинглау | ТР Хезмәт министрлыгы, РРУ | озак вакыт карау системасы кысаларында күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты буенча хисап | декабрь | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7.3. | Татарстан Республикасында пилот проектын тормышка ашыруны анализлау һәм өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ТР Цифра министрлыгы | җыелма информацион-аналитик материал | декабрь | - | агымдагы финанслау |
| Барлыгы | | | | | 68 044,1 | 15 960,9 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

Казан төзелеш көллияте – «Казан төзелеш көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;
«РММАҮ» ДАССУ – «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
ДКУ – дәүләт казна учреждениесе;
ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты;
ДССУ – дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе;
КДМА – Казан дәүләт медицина академиясе – Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия медицина өзлексез һөнәри белем бирү академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе филиалы;
ТР Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;
ХСХККҮ – халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге;
ТР ССМ – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ТР Цифра министрлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;
ТР Хезмәт министрлыгы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
ККО – коммерциягә карамаган оешма;
РФ ПФның ТР буенча бүлеге – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге;
РРҮ – «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе;
ККСЮО – коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмалар;
СХКУ – социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре;
ИТҮ – инвалидларны тернәкләндерү үзәге.